БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

# ДУСЛЫК

КПССның ОКТЯБРЬ РАЙКОМЫ ҺӘМ ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ РАЙОН СОВЕТЫ ОРГАНЫ

ОРГАН ОКТЯБРЬСКОГО РАЙКОМА КПСС И РАЙОННОГО СОВЕТА НАРОДНЫХ ДЕПУТАТОВ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №23 (7040) | 22 февраль, 1990 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 3 тиен.

## Котлы булсын өегез

Норлат автотранспорт предприятиесе яңа 36 фатирлы йортны эксплуатациягә тапшырды. Бу йортның төзелеп беткәнен предприятие коллективы 6 ел көтте. Фатирлар беренче чиратта сугыш һәм хезмәт ветераннарына бирелде. Шуларның берсе—предприятиедә 30 ел эшләгән хезмәт ветераны Гаяз Галиуллович Галиуллин.

x x x

«Норлатнефть» НГДУсы хезмәт коллективында да өй туйлары булды. 53 нче СМУ төзүчеләре 60 фатирлы өйне файдалануга тапшырдылар.

● КПСС Үзәк Комитеты платформасы: фикерләр һәм тәкъдимнәр

## Вакытында чик куярга

КПСС Үзәк Комитетының бөтенхалык тикшерүенә чыгарылган партиянең чираттагы съездына платформасы проекты гуманлы, демократик социализмга чакыручы документ булып тора. Әмма мин текстта таркау һәм конкрет булмаган пунктларны да очратам. Болар элита турында сүз алып баруда да чагыла.

Мисал өчен проектның икенче бүлегенең соңгы фразасын алыйк. Анда «Хезмәт хәленнән явыз ният белән файдалануларның тамырын корытырга» диелгән. Ә аңа, ягъни платформага кадәр бу кагыйдә юк идеме? Һәм ни өчен партия бу явызлыкның шундый тирән һәм киң күләмнәрдә таралуына, социаль гаделлек турындагы төшенчәнең тулысынча юкка чыгуына юл куйды?

Бу фразаны түбәндәгечә үзгәртүне зарури саныйм. «Хезмәт хәленнән явыз ният белән файдалану партия члены булу белән сыеша алмый һәм уголовный тәртиптә җәзалана».—дип язу дөрес булыр иде. Халыкта катгый ризасызлык тудыручы бу күренештән башкача котылу мөмкин түгел.

Минем икенче искәртмәм «Партияле массовый информация чаралары турында»гы пунктка кагыла. Биредә, минем карашымча, матбугатны оештыруның ленинчыл принципларыннан тайпылуга юл куела. Партия басмаларының һәм башка партияле үзәк массовый информация чараларының редакторлары тиешле дәрәҗәдәге пленумнарда түгел, ә съездларында сайлануы һәм аларга гына отчет бирүен дөрес саныйм. Бу партия матбугатының абруена, аның тәэсирлеге үсүгә уңай йогынты ясар иде.

Тулаем платформа проектын яклыйм һәм сүздән эшкә күчәргә вакыт икәнлеген белдереп узасым килә.

**В. ВЕРИН,**
1945 елдан КПСС члены.
Норлат шәһәре.

## Ошамады

Мәскәүдә үткән КПСС Үзәк Комитеты Пленумы барышын зур түземсезлек белән карап бардым. Комсомол эшендәге кеше буларак, мине, әлбәттә, яшьләр мәсьәләсе кызыксындырды. Кызганычка каршы, моңарга хәтле булып үткән сессияләрдә, соңгы февраль Пленумында бу темага кагылучылар булмады. Залда утыручы комсомол депутатларының «йоклап» утыруларына гаҗәпләндем мин. Башкарылмаган күпме эшләребез бар!.. Аннан, яшьләр турында Закон чыгаруны да тизләтсеннәр иде.

Күпчелек ораторларның күпме матур сүзләр белән генә чикләнеп калулары да ошамады.

**И. КУЛИКОВ,**
ВЛКСМ райкомының беренче секретаре.



## Алдынгыларның берсе

«Кондырча» колхозында эшләүче уңган сыер савучы, III дәрәҗә Хезмәт Даны ордены кавалеры Бибинур Вәлиеваны авылда гына түгел, районда да яхшы беләләр. Ул шулай тырыш хезмәте аркасында хөрмәт казанды. 1964 елдан бирле фермада хезмәт куючы бу тыйнак хатын тапшырылган эшне һәрчак җиренә җиткереп, зур намуслылык хисе тоеп башкара. Аның эшеннән һәрчак канәгать калалар.

Бибинур Вәлиева узган елны һәр сыердан 3546 килограмм сөт сауды. Агымдагы елда да сынатмаска исәпли ул.Шуның өчен сыер савучы Мөнәвәрә Ишниязова белән бер группада уртак тырышлык, икеләтә энергия куеп эшлиләр. Аларның январь ае күрсәткечләре дә начар булмады.

Бибинурның тормыш иптәше Хәйдәрне дә колхозда мактап кына телгә алалар. Аларның аренда звеносы узган ел бөртекле һәм бөртекле-кузаклылардан гектарыннан 27,7 центнер уңыш алуга иреште һәм район буенча беренчелекне алды.

Менә шулай, һәрчак алдынгыларның да алдынгылары гына булырга телиләр алар.

Рәсемдә: сыер савучы В. Вәлиева.

Л. Шәмсуаров фотосы.

## Җыелыш эшлекле төстә үтте

«Комбайн» колхозында отчет җыелышы узды. Идарә отчетын колхоз председателе Әхтәм Минсалихович Шәрәфетдинов ясады. Докладта ул хуҗалыктагы һәр тармак эшенә тукталды, уңышларны, кимчелекләрне җентекләп анализлады, алга куелган максатны билгеләп үтте. Агымдагы елда колхоз 100 сыердан 98 бозау,100 сарыктан 105 бәрән, бер ана дуңгыздан 20 бала, мөгезле эре терлектән 650—700 грамм тәүлеклек артым, һәр гектардан 21 центнер уңыш алырга, Чурабатыр авылына каты түшәүле юл салырга, терлекчелек биналарын механикалаштырырга һәм реконструкцияләргә ниятли.

Фикер алышуда баш агроном Р. Гыймранов, баш механик Җ. Әгъләмов, баш зоотехник Р. Ибәтуллин үзләре җитәкләгән тармактагы эшнең торышы турында сөйләделәр. Фикер алышуларда шулай ук колхозчылар да катнаштылар. Алар эшне тагын да яхшырту йөзеннән үзләренең эшлекле тәкъдимнәрен керттеләр.

Отчет җыелышында район агропромышленность берләшмәсе председателе иптәш Х. Х. Гатин катнашты һәм чыгыш ясады.

**Ә. ФӘССАХОВ,**
партоешма секретаре.

## *Очрашу җанлы узды*

19 февральдә 225 номерлы Биләр Озеро сайлау округы буенча ТАССР халык депутатлыгына кандидат КПСС райкомының беренче секретаре Х. Х. Морадыймов Муса Җәлил исемендәге колхозның Кәкре Атау бригадасы сайлаучылары белән очрашты. Очрашуда округ сайлау комиссиясе секретаре Р. Х. Кәлимуллин, депутатлыкка кандидатның ышанычлысы П. Я. Генералов иптәшләр дә катнашты. Очрашуны колхоз партия комитеты секретаре Т.Г. Вәлиуллин ачты.

Аннан соң сүз алган Хәлил Хәмзиевич илебездә мөһим политик кампания —сайлауларга хәзерлек барышына, аны оешканлык һәм активлык шартларында үткәрү мәсьәләләренә тукталды.

Залда утырган халык —колхозчылар, авыл интеллигенциясе вәкилләре, хезмәт ветераннары, авылның социаль үсешенә игътибарны көчәйтү кирәклеген күрсәтеп уздылар. Депутатлыкка кандидатка сораулар да күп булды. Алар юлларга таш җәю, фермага сөт үткәргечләр кую, производство объектларын һәм торак пунктларны электр энергиясе белән тәэмин итүне яхшырту мәсьәләләренә кагылышлы иде. Хәлил Хәмзиевич аларның сораулары игътибарга алыначагы, бу мәсьәләдә тиешле ярдәм күрсәтеләчәге турында әйтеп үтте.

Очрашу барышында колхозчылар бригада базасында мөстәкыйль хуҗалык оештыруны күтәреп чыктылар. Бу мәсьәлә буенча фикер алышуларда уннан артык колхозчы һәм хезмәт ветераны чыгыш ясады. Алар барысы да шушы фикерне якладылар һәм башка авылдашларының да шул теләктә икәнлеген белдерделәр.

Х. Х. Морадыймов бу мәсьәләне киләчәктә уңай хәл итәргә мөмкин булуы турында белдерде.

## ҺӘММӘБЕЗ ӨЧЕН КИРӘКЛЕ ХЕЗМӘТТӘ

Район Советы башкарма комитеты каршындагы күп тармаклы производство предприятиесе карамагында 24690 квадрат метр торак мәйдан, зур сүүткәргеч линиясе һәм коммуналь учреждениеләр, тәүлегенә 4 мең куб метр куәтле суны чистарту корылмасы, тәүлегенә 7,2 мең куб метр су кудыручы насос станциясе тора. Моңардан тыш аның вазифасына шәһәрне санитария ягыннан чиста тоту, авария - диспетчерлык службасын тәэмин итү бурычы һәм башкалар керә.

Коллектив узган елны уңышлы тәмамлады. Хезмәт күрсәтүдән 451,7 мең сумлык керем алынды, план 150 процентка үтәлде. Халыкка план буенча 30,9 мең сумлык хезмәт күрсәтелде. Мәктәпләргә, балалар бакчаларына, көнкүреш йортларына 176,2 процент күләмендә коммуналь-көнкүреш хезмәте күрсәтелде.

Ә тармаклар буенча план үтәлеше түбәндәгечә: су белән тәэмин итү планы —171,5, аны чистарту—129, кунакханә —117 һәм мунча хезмәте күрсәтү 118 процентка үтәлгән.

Коллектив агымдагы елда да сынатмый. Хәзерге вакытта тармак эшчеләре язгы ташу чорында үз коммуникацияләренең җимерелүен кисәтү йөзеннән түбәләрне кардан чистарту, торак фондын тәртиптә тоту, чүп-чар калдыкларның күп туплануыннан саклау кебек чараларны башкаралар.

Һәрвакыттагыча транспорт шоферлары (бригадиры В. М. Кузнецов) үз эшләренә намус белән карыйлар. Көн саен иртәнге 5 сәгать 30 минутта шоферлар А. Н.Мокин, Р. Г. Кәримов, А.И. Кәримов, Р. Н. Әсәров, Н.С. Ефремов чүпне алырга киләләр. Аларның барысы да үз участокларына әйбәт хезмәт күрсәтәләр, транспортны эффектлы файдаланалар. Электриклардан исә аерулча Николай Семенович Хвалеевны билгеләп үтәсе килә. Ул кимчелекләрне бетерү йөзеннән халык биргән заявкаларны төгәл үти һәм аның адресына әлегә кадәр бер генә шикаять дә булмады.

Безнең тармак эшчеләренең профессиональ бәйрәмнәренә дә ерак калмады. Аңа яхшы күрсәткечләр белән килүебез —коллективның төп максаты.

**Н. СИДОРОВА,**
МПП торак участогы мастеры.

# «Күңелемә авыл якын...»

## Безнең кандидатлар

Лениногорскига сайлаучылар белән очрашуга баргач, 868 нче округ буенча РСФСР халык депутатлыгына кандидатларның берсе —Мусин, программада каралмаган булса да, беренче мөмкинлек булуы белән автомәктәп коллективына килде. Моның сере бик гади—моннан 15 ел элек, хәрби хезмәт срогын тутырып кайткач, биредәге мәктәптә шоферлыкка укыды, чөнки ул чакта. Октябрь районында бу төр һөнәргә өйрәтү оештырылмаган иде әле.

Мәктәп укытучылары, курсантлары Миндамир Мәхмүтовичны җылы каршыладылар. Арада аны бу һөнәргә өйрәткән Н. Ф. Углов та бар иде. Николай Филиппович әлеге очрашуның үзәгендә торды. Шулай булмыйни: шәкертенең республика хөкүмәте членлыгына кандидат итеп күрсәтелүе өлкән яшьтәге педагог өчен сөенеч иде, әлбәттә.

Кандидатның үзе укыган мәктәпкә килүе күпләр өчен бик гади деталь тоелыр. Әмма Миндамир Мәхмүтович турында сөйләгәндә моны читләтеп үтү мөмкин түгел —бу, ягъни максатчанлыгы —аның үҗәтлеген күрсәтеп торучы фактор. Малай чактан хирес иде ул автомобильгә. Хәер, үсмерләрнең һәркайсына «тимер җене кагылган» була, әмма Миндамир өчен арада иң күңел ятканы —машина. Башлангыч мәктәптә укыганда ук туганнантуган абыйсы Нариман Хисамов янында көннәр буе юана: юлдаш булып утырып йөри, хәлдән килгәнчә булыша—өйгә тузан, майга буялып һәм, билгеле инде, кичегеп кайтып керә. Әнисеннән (әтисе гел эштә) еш кына эләккәли дә.

Мәхмүт Мортазович, әтисе—техникум, кырык яшенә җиткәч институт тәмамлаган экономист—Миндамир белән укуын дәвам итү хакында ул елларда шактый еш әңгәмә алып бара. Улы үзенекен итә.

—Тегe яки бу тармакта урта кул белгеч булганчы, үз кулың белән эшләүне алын күрәм,—ди ул бу уңайдан.

Ә эшкә килгәндә, аны куш инде, өйрәтеп, боерып торганны көтми, үзе белеп башкара.

Үткән ел март аенда ул эшләгән автогараж аренда мөнәсәбәтләренә күчте. Партгрупорг, партта иң тәҗрибәле шоферлардан берсе Мусин яңалыкны кертүнең инициаторы иде.

—Әлегә еллык экономик күрсәткечләре әзер булмаса да, яңача эшләүнең өстенлекләре күз алдында,—ди мөгезле эре терлекләр симертү буенча хуҗалыкара берләшмәнең партия бюросы секретаре К. М. Мусин. —Дисциплина ныгыды, җитештерүчәнлек күпкә үсте.

Миндамир Мәхмүтович, аның фикерен тулыландырып, автопаркта хезмәтне яңача оештыру тәртибен конкрет аңлата. Элек, мәсәлән, машинасы ватылса һәм аны төзәтү өчен запас часть булмаса шофер тыныч күңел белән өенә кайтып китә. Үткән җәй исә, керем-чыгымнарны исәпкә алуның чек формасы кертелгәч, мондый гадәт үзеннән-үзе бетерелә: рейстан буш һәр шофер гаражны төзекләндерү һәм җиһазлауда эшли. Чөнки бу эшкә читтән осталар чакырылсалар, чыгымнар коллектив өстенә төшә бит. Барлык эшне шоферлар шулай үзләре башкарып чыгалар.

Күмәк җаваплылыкның икенче ягы да отышлы. Арендачылар төзек машинаның буш торуына һич юл куймыйлар. Шоферы ялда, яисә чирли икән, элек машина тик тора. Хәзер моңа һич юл куелмый, буш хезмәттәше утыра, чөнки уртак нәтиҗәгә эшләгәч, файдасы да уртак бит. Яңалык кертелгәч, техниканы бушка куу үзләгеннән бетә.

Моның реаль нәтиҗәләре күз алдында. Берләшмә карамагындагы 18 йөк автомобиле хуҗалык ихтыяҗларын тулы канәгатьләндерә. Һәм якшәмбе көннәрендә шоферларның зур күпчелеге, 90 процентка якыны, рәхәтләнеп ял итә.

Ял дигәннән, Мусин аңа күнекмәгән: диванда ятып, эшсез каңгырап йөрүне белми, хезмәтен алмаштыру аңа үзе ял. Шуңа рейстан кайтуга, законлы ял көннәрендә дә һич тик тора белми. Берләшмә салган йортка башка чыккач, әлек үз кулы белән каралтыкурасын корды, бер очтан бакча булдырды. Карлыган, кура, җир җиләге түтәлләре мәйданын киңәйтә бара. Җәен кызлары, хатыны Гөлнур белән шул бакчада мәш килә. Гөлнурның, сүз җаеннан әйткәндә, иренә охшаш сыйфатлары байтак. Тыйнак, иренә абруй өчен түгел, күңеле тартkан хезмәтне күңел күреп башкара. Оператор булып эшләгән чагында, китапханәче итеп күчергәннәр иде, үзе сорап яңадан фермага кайтты. Анда, кулы яхшы белгән эштә, сынатмый иде. Хезмәттәшләре аны да халык депутатлыгына кандидат итеп күрсәттеләр. Авыл Советына.

Кулы тик тормаска күнеккән кешегә кышын да эш табыла. Үзе ишеткән, күргән яңа антеннаны ясамый калмый. Шуңа дүрт каналдан төрле программаларны карый. Радиотехниканы яхшы белә, хезмәттә чакта радист иде. Кренкель исемендәге Мәскәү үзәк радиоклубы белән даими элемтәдә тора.

...Сайлау алды җыелышлары башлангач, КПСС райкомы (ул аның члены) пленумы Мусинны РСФСР халык депутатлыгына кандидат итеп күрсәтте. Бер мандатка өч кандидат дәгъвалык иткәч, Миндамир Мәхмүтовичка сайлаучылар алдында җавап тотканда, үзе әйтмешли, «тирән тамызырга туры килә». Нигә дисәң, көндәшләре икесе дә югары белемле, ә ул гади шофер. Әмма югалып калмый ул.

—Мин авылда туып-үскән кеше, шуңа авыл проблемаларын хәл итүне беренче чираттагы бурычым саныйм,—ди Миндамир Мәхмүтович. —Ә авылда еллар буе хәл ителми килгән мәсьәләләр күп. Шуның иң мөһиме игенчене чын хуҗа итү, ягъни җиргә кире кайтару кирәк. Моңа аренда һәм башка прогрессив алымнарны кулланганда гына ирешергә мөмкин.

Шуңа күрә аның платформасының үзәгендә бу мәсьәлә. Әлбәттә, халыкны кызыксындырган башка актуаль мәсьәләләр —газ кертү, асфальт юллар җәю, балаларга, хатын-кызларга, ветераннарга аерым игътибар бирү кирәклеге һәм башка күп нәрсәләрне дә эченә ала. Яшьләрне борчыган, шәһәр халкы хәл итүне көткән проблемалар да аны уйландыра, экология мәсьәләләре дә күңелендә урынлы борчу тудыра. Мусин аларны авыл, район күзлегеннән чыгып кына түгел, тулаем регионда хәл итү яклы.

Депутат итеп сайлана калса, ул вәгъдәсен үтәргә сәләтле, принципиаль һәм тырыш, тынгысыз, таләпчән һәм үҗәтлеге дә җитәрлек.

**Р. АЙЗАТУЛЛИН.**



**Борис Дмитриевич Шувалов Синдряков исемендәге колхозда тәҗрибәле механизаторлардан санала. Бүгенге көннәрдә ул хуҗалыкта ферма малларына салам ташу, колхоз делянкасыннан халыкка утын кайтару белән мәшгуль. Җәйгә чыкса тагын да мөһимрәк участокка— икмәк язмышы хәл ителгән басуга эшкә китә. Бай тәҗрибәсе, хезмәтенә бирелгәнлеге үзенә йөкләтелгән һәр эшне намус белән үтәргә мөмкинлек бирә. Коммунист Шувалов нинди генә вазифа башкарса да хезмәттәшләренә үрнәк булып тора.**

**Рәсемдә: Б. Д. Шувалов колхозның техника паркында. С. Казакова аны җәйге кыр эшләре кызган чакта рәсемгә төшергән булган.**

## Лаеклы ялга

Күптән түгел Кычытканлы авыл культура йортында колхозчыларның гомуми җыелышы уздырылды. Клуб эче халык белән тулы иде. Җыелышта беренче сүзне колхоз рәисе Җ. З. Нургалиев алды. Ул башкарган эшләргә йомгак ясады һәм киләчәккә бурычлар белән таныштырды.

Аннан соң көчле алкышлар астында хезмәт алдынгыларына, пенсия яшенә җитеп лаеклы ялга китүчеләргә акчалата премияләр һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырылды.

**З. ИСМӘГЫЙЛЕВА.**

# КӨЧЛЕЛӘР ЭШЕ

Кышкы матур бер көндә үзегезне усак урманына килеп кергәндәй хис итегез әле. Тирә-юньдә серле тынлык. Баш өстеннән ак болытлар агыла. Борынны саф һава ярып керә, ничектер сулыш алуы да җиңел.

Октябрь урман промышленносте хуҗалыгының агач складында әнә шундый күңелгә балачактан яхшы таныш атмосферага юлыгасың. Ул агач складында исемен йөртсә дә, гадәти склад түгел: биредә барлык төр эш тә ачык һавада башкарыла.

Әнә бер читкә ботаклары да чабылмаган агачларны китереп өйгәннәр. Аларны эшкәртеп халык кулланышы һәм промышленность товарлары өчен җибәрәчәкләр.

Нинди генә агач булмасын, ул иң беренче чиратта моторист кулыннан узачак. Аннан берничә төркемгә бүленгән ир-ат аны үлчәп аера һәм транспортерга төшерә, ә транспортердан исә сортларга аералар. Рафик Хаҗимөратов бригадасы егетләренә көн саен менә шундый төр авыр һәм күп көч сорый торган эшне башкарырга туры килә икән. Йөкчеләргә дә җиңел түгел. Төрле һава шартларына булуга да карамастан, аларга вагоннарны үз вакытында төяп җибәрергә кирәк. Шунлыктан Рафик Галимов, Рафаэль Вәлиәхмәтов кебек таза беләкле ир-атлар эшләреннән бер генә минутка да тукталмыйлар. Автокран да көтми. Тимер юлның икенче ягыннан озатылган төргәк-төргәк йомычкаларны бирге яктан вагоннарга озатып кына тора. Кайчакларда һавадагы авыр әйберне күреп йөрәк төшеп киткәндәй була. Әгәр дә өзелеп төшсә?

—Әйе, —ди унберенче елын хезмәт куючы Виктор Афанасьев. —Автокранның мәгезенә йөкне аннан-моннан гына элеп куйсаң, өзелеп төшү ихтималы бар. Бәхеткә каршы бездә әле мондый бәла-казаның булганы юк...

Ярым караңгы цех эченә үтәбез. Бу бер дә күз күреп күнеккән цехларга охшамаган. Агач стенага кеше буйлыгы тар гына уем уйганнар. Шуннан цехка эшкәртеләчәк агач төпләрен кертүләр икән. Янәшә генә берничә станок тора. Эшче Рим Шәйдуллин белән танышабыз:

—Зарлана димәгез,—ди ул. Бик авыр безгә. Көн саен күпме агач сөйрәп керергә кирәк.Ә бит боларның һәммәсен кул көче белән эшлибез. Безнең эшне җиңеләйтү өчен берәр төрле чара табасы иде. Монысы гына бер хәл, агач артыннан йөреп күпме вакыт үтә.

Безнең әңгәмәгә колак салган эшчеләр дә станокларның иске маркалы булуыннан һәм аның еш ватылуыннан зарландылар. Шулай булса да, үзләре норманы 120—130 процентка үтәп баралар икән: «Тырышабыз, безнең яктан тоткарлык булмас анысы», —диештеләр алар. —Төзәтеп булырлыгын гына төзәтербез».

Урман промышленносте хуҗалыгының агач складында хатын-кызлар да эшли. Дөрес, алар беркадәр җиңелрәк хезмәтне башкаралар: промышленность товарлары өчен әрҗәләр, Мәскәү сәгать заводына сәгать корпуслары һәм башка әйберләрне ясыйлар. Биредә дә станоклар: агачны зурлыгына карап үлчәп, төгәл итеп кисәләр, ышкылыйлар. Эштән чыгарылган продукциянең үз эталоннары булдырылган.

—Бездә дә хезмәт осталык һәм җаваплылык сорый,—диде бригадир Зоя Константиновна.

—План да урманга карап үтәлә. Урман бирсәләр, үтибез, бирмәсәләр юк.

Кыскасы, кайсы гына участокка килеп чыксаң да, авыр хезмәтне башкаручы көчле һәм түземле кешеләр белән очрашасың.

Цех начальнигы А. В. Баранов үзе җитәкчелек иткән хезмәт коллективы турында җылы итеп сөйләде. Аннан җитешсезлекләргә күчте:

—Беләм,—дип дәвам итте ул.—Эшчеләр хезмәт шартларыннан зарланганнардыр. Әйе, бездә автомат һәм ярымавтоматлар юк, ләкин бик теләсәк тә без аларны сатып ала алмас идек. Чит ил валютасында бик кыйммәт —400 мең сумнар тирәсе тора. ФРГда бездәге кебек предприятиедә 40 эшче көч тотылса, бездә ул икеләтә артып китә. Әле җитешми дә. Аннан, эшчеләрнең эштә инициатива күрсәтергә бик үк ашыкмауларын да билгеләп үтәр идем. «Тегеләй эшлик, болай итик», дип берәүнең дә минем янга килгәне юк әле. Өстән күрсәтмә бирелсә, шулай эшлиләр, бирелмәсә юк. Рационализаторлык тәкъдимнәре дә аз керә. Эшне җиңеләйтү юлларын үз эшчеләребез эзләп тапса, нинди яхшы булыр иде...

Экономист Гөлфия Шәфигулловна Гаффарова безне план үтәлеше белән таныштыра. Зоз Разыграева, Николай Герасимов, Замир Хисамов, Фәйзинур Зарипов, Минекәй Хәлиуллин бригадалары эшкәртелгән товар продукциясе җитештерү һәм башка төр планнарны 120—117 процентка арттырып үтәгәннәр. Халык куллануы товарлары планы —102, ә көнкүреш хезмәте күрсәтү 105 процентка үтәлгән. Ләкин аның киләчәк үсеше өчен тагын да зур мөмкинлекләре бар.

**Г. РӘХИМОВА.**

